Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы Татарстан Республикасы

Кукмара муниципаль районы

**карар**

2023 елның 07 ноябре №117

Кукмара муниципаль районының
Зур Кукмара авыл җирлеге
муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану
һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 31 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына, муниципаль берәмлектә ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган Зур Кукмара авыл җирлеге карар итәм:

1. «Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Кукмара муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. «Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карар проектын әзерләү комиссиясе тарафыннан 2023 елның 17 ноябреннән 4 декабренә кадәр экспозиция һәм Җыен үткәрү юлы белән ачык тыңлау үткәрергә.

3. Халык тыңлауларында катнашучылар җыелышын үткәрү 4 декабрьгә 15.00 сәгатьтә Зур Кукмара авылы КФҮ бинасында Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча билгеләнергә тиеш.

4. ««Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»» карар проекты экспозициясен һәм аңа мәгълүмат материалларын 2023 елның 17ноябреннән 4 декабренә кадәр Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 2 йорт адресы буенча Зур Кукмара авыл башкарма комитеты бинасында үткәрергә;

5. Экспозициягә килүчеләргә консультацияне экспозиция урнаштырылган урын буенча түбәндәге график буенча үткәрергә: сишәмбе һәм пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр, 13.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорда.

6. Билгеләү:

- «Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карар проекты Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырыла: http://kukmor.tatarstan.ru// 2023 елның 8 ноябреннән дә соңга калмыйча;

- карарның 1 пунктында күрсәтелгән карар проекты буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне ачык тыңлауларда катнашучылар 2023 елның 4 декабренә кадәр ««Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карар проектын әзерләү комиссиясенә түбәндәге адрес буенча язма рәвештә кертә алалар: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Зур Кукмара авылы, Мәктәп урамы, 2 йорт, шулай ук язма һәм халык тыңлауларында катнашучылар җыелышы барышында телдән.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җирлек башлыгы Р.Р.Хәнәфиев

ОГРН 1061675010957
ИНН 1623008458

Кушымта
проект

# КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Кукмара муниципаль районының
Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль
берәмлегенең җирдән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Кукмара муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, ачык тыңлаулар протоколын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы карар чыгарды::

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципальберәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен кушымталар нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: www.pravo.tatarstan.ru һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет»мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кукмара муниципаль районы Советының шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы С.Д.Димитриев